ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**13.12.2024**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 4728**

Педагогик хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә грант турында

Педагогик хезмәткәрләрне белем бирү системасына җәлеп итү һәм педагогик потенциалны үстерү, югары нәтиҗәләргә ирешүгә мотивацияләү, Зеленодольск муниципаль районы муниципаль белем бирү оешмаларының яшь белгечләренә матди ярдәм күрсәтү максатларында, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Педагогик хезмәткәрләргә – Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе ведомствосындагы муниципаль белем бирү оешмаларының һәм балаларга өстәмә белем бирү оешмаларының яшь белгечләренә «Яшь белгеч» гранты (алга таба – «Грант») булдырырга.
2. Түбәндәгеләрне расларга:
2.1. «Яшь белгеч» гранты турында нигезләмә (1 нче кушымта);
2.2. «Яшь белгеч» грантына дәгъва кылучыларны сайлап алу буенча конкурс комиссиясе составы (2 нче кушымта);
2.3. «Яшь белгеч» грантына дәгъва кылучыларның конкурс нигезендә сайлап алу критерийлары(3 нче кушымта);
2.4. «Яшь белгеч» грантына дәгъва кылучыларны конкурс нигезендә сайлап алуны уздыру сроклары һәм тәртибе (4 нче кушымта).
3. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсенә түбәндәгеләрне оештырырга һәм тәэмин итәргә:

белем бирү эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру ысулларын һәм технологияләрен куллану буенча һөнәри-психологик әңгәмә һәм индивидуаль проектларны сайлап алу критерийлары нигезендә комиссия составында хезмәткәрләр эшен;

«Яшь белгеч» грантына дәгъва кылучыларның гаризаларын карауга бирелгән сроклар кысаларында белем бирү эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру ысулларын һәм технологияләрен куллану буенча индивидуаль проектлар экспертизасын һәм конкурс комиссиясенә экспертиза нәтиҗәләре турындагы белешмәләрне җибәрергә.

әлеге карар белән расланган тәртиптә, срокларда һәм сайлап алу критерийлары нигезендә «Яшь белгеч» грантына дәгъва кылучылар белән һөнәри-психологик әңгәмә үткәрү;

«Яшь белгеч» грантына дәгъва кылучыларның заявкаларын кабул итү һәм теркәү.

4. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе ведомствосындагы белем бирү оешмалары һәм балаларга өстәмә белем бирү оешмалары җитәкчеләренә түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

белем бирү оешмаларының һәм балаларга өстәмә белем бирү оешмаларының кадрлар ихтыяҗын һәм грант алу өчен заявка биргән вакытка 35 яшькә җитмәгән һәм белгечлеге буенча педагогик эшчәнлек стажы өч елдан да артмаган педагогик хезмәткәрләрнең потенциалын өйрәнергә;

грантына дәгъва кылучыларның грантны гамәлгә ашыру шартлары белән таныштырырга;

белем бирү эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру ысулларын һәм технологияләрен куллану буенча индивидуаль проектны әзерләүдә грантына дәгъва кылучыларга булышлык күрсәтергә (индивидуаль проектны эшләү өчен грантына дәгъва кылучыга остаз билгеләргә);

грантына дәгъва кылучыларның заявкаларын җыюны оештырырга һәм конкурска бирергә.

5. Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге башлыгына әлеге карарны Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының (http://pravo.tatarstan.ru)рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) сайтында урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкче урынбасары - Мәгариф идарәсе башлыгы Р.В. Афанасьевага йөкләргә.

Җитәкче З.Ф. Хәбибуллин

Татарстан Республикасы
Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2024 елның 17 декабрендәге
4728 номерлы карарына
1 нче кушымта

«Яшь белгеч» гранты турында
**НИГЕЗЛӘМӘ**

1. Әлеге Нигезләмә «Яшь белгеч» грантын (алга таба - грант) бирү максатларын, шартларын һәм механизмнарын билгели.

2. Грант конкурс нигезендә сайлап алу нәтиҗәләре буенча бирелә. Конкурс Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба - Башкарма комитет) боерыгы нигезендә уздырыла.

3. Башкарма комитет грантын бирү тиешле финанс елына Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджетында тиешле максатларга каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла.

4. Грант бирүче - Башкарма комитет һәм Гомумроссия белем бирү профсоюзының Зеленодольск территориаль оешмасы (килешү буенча).

5. Әлеге Нигезләмәдә аны куллану максатларында түбәндәге терминнар кулланыла:

грантка дәгъва кылучылар -конкурс нигезендә сайлап алу уздыру вакытына 35 яшькә җитмәгән һәм белгечлеге буенча өч елдан артык булмаган педагогик эш стажына ия булган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы территориясендә урнашкан, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе ведомствосындагы муниципаль белем бирү оешмаларының һәм балаларга өстәмә белем бирү оешмаларының педагогик хезмәткәрләре (алга таба-педагогик хезмәткәрләр);

грант алучы-конкурс нигезендә сайлап алу йомгаклары буенча грант бирү турында карар кабул ителгән грантта дәгъва кылучы;

эш бирүче - Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы территориясендә урнашкан, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе ведомствосындагы муниципаль белем бирү оешмасы

Вәкаләтле орган - Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе.

6. Грант бер мәртәбә түләнә һәм Россия кредит оешмасында ачылган грант алучының счетына күчерелә.

Грант алучылар өчен грант күләме түбәндәгечә тәшкил итә:

- Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына күрсәтелгән максатларга бүлеп бирелгән акчалар исәбенә 50 000,0 (илле мең) сум.

7. Зеленодольск муниципаль районы бюджетында грант алу өчен бюджет ассигнованиеләре булмау грант алуга сайлап алуны үткәрмәү өчен нигез булып тора.

8. Ел саен 50дән артык булмаган грант бирелә.

9. Грант бирүнең максаты – Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы территориясендә урнашкан, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе ведомствосындагы муниципаль белем бирү оешмалары һәм балаларга өстәмә белем бирү оешмаларының педагогик хезмәткәрләрен югары нәтиҗәләргә ирешүгә, педагогик хезмәткәрләргә-яшь белгечләргә матди ярдәм күрсәтүгә мотивация.

10. Грант бирү шартлары булып түбәндәгеләр тора:

Вәкаләтле орган тарафыннан оештырыла торган грант алу өчен сайлап алу нигезендә җиңү;

педагогик эшчәнлекнең югары нәтиҗәләренә ирешүгә һәм үстерүгә юнәлдерелгән проектны гамәлгә ашыру.

11. Грантка дәгъва кылучыларны сайлап алу конкурс комиссиясе тарафыннан гамәлгә ашырыла. Конкурс комиссиясе составы Башкарма комитет тарафыннан раслана. Конкурс комиссиясе, рәисне дә кертеп, кимендә 5 әгъзадан торырга тиеш.

12. Вәкаләтле орган:

- сайлап алу турында, грантка дәгъва кылучыларга карата таләпләр турында, сайлап алу сроклары турында – сайлап алу башланырга җиде көннән дә соңга калмыйча, сайлап алу йомгаклары турында -сайлап алу тәмамлану датасыннан җиде көннән дә соңга калмыйча, мәгълүматны «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендәге (https://edu.tatar.ru/z_dol/zelenodol) рәсми сайтында бастырып чыгаруны тәэмин итә;
- заявкаларны кабул итүне һәм теркәүне, җиңүчеләрне сайлап алуны һәм билгеләүне оештыра;
- грант бирү турында йә грант бирүдән баш тарту турында карар кабул итә һәм аны Башкарма комитет карары белән раслый;
- грант бирү турында килешү төзелә (алга таба - килешү).

13. Конкурс нигезендә сайлап алуда катнашу өчен грантка дәгъва кылучылар Вәкаләтле органга түбәндәге документларны тапшыралар:

- әлеге Нигезләмәгә 1 нче кушымтадагы форма нигезендә грант алуга конкурста сайлап алу өчен катнашуга форма буенча заявка (алга таба - заявка);
- эш бирүчедә уку процессы нәтиҗәлелеген арттыруның инновацион алымнарын һәм технологияләрен гамәлгә кертү проекты (алга таба - проект);
- эш урыны буенча таныкланган грамоталарның, сертификатларның, дипломнарның һәм башка документларның (алар булса) күчермәләрен үз эченә алган портфолио;
- грантны алу өчен катнашучының һөнәри казанышлары турында мәгълүмат булган белешмә;
- әлеге Нигезләмәгә 2 нче кушымтадагы форма буенча персональ мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык;
- эш бирүче тарафыннан хезмәт кенәгәсенең таныкланган күчермәсен;
- фамилиясен, исемен, атасының исемен (булган очракта), теркәлү урынын күрсәтеп, паспорт күчермәсен;
- югары белем бирүче белем бирү оешмасы, педагогика көллияте дипломы күчермәсен,
- аспирантура һәм фәннәр кандидаты дипломы күчермәсен (булган очракта);

- сайлап алуны үткәрү датасына кадәрге айның беренче числосына грант алырга теләүченең салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар һәм процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурычы булмавын раслый торган салым органыннан белешмә.

14. Вәкаләтле органга кергән заявка кергән көннән алып бер эш көне эчендә теркәлә.

15. Заявкаларны карап чыгу, әлеге Нигезләмәнең 13 пунктында күрсәтелгән кушып бирелгән документлар белән заявкаларны кабул итү срогы тәмамланган көннән алып җиде эш көне эчендә, конкурс комиссиясе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Конкурс комиссиясе эше утырышларда башкарыла. Конкурс комиссиясе утырышы, әгәр анда әгъзаларының яртысыннан да ким булмаган өлеше катнашса, хокуклы дип санала.

Конкурс комиссиясе карары, конкурс комиссиясе утырышында катнашучыларның күпчелек тавышы белән, ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, рәиснең тавышы хәлиткеч булып тора.

Конкурс комиссиясе карары конкурс комиссиясенең барлык әгъзалары һәм аның рәисе тарафыннан имзаланган беркетмә белән рәсмиләштерелә, аңа әлеге Нигезләмәнең 17 пункты нигезендә сайлап алу җиңүчеләре исемлеге кушымта итеп бирелә.

Конкурс комиссиясе карары, беркетмәгә имза салынган көннән алып бер эш көненнән дә соңга калмыйча, Вәкаләтле органга тапшырыла.

Вәкаләтле орган беркетмәне алган көннән эш көннәре исәпләнә торган өч көн эчендә грант бирү турында карар кабул итә һәм Башкарма комитет сайлап алуда җиңүче дип танылган грант алучыларга грант бирү турында боерык чыгара.

16. Грантка дәгъва кылучыларны сайлап алу нигезендә катнашудан баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

- Грантка дәгъва кылучыларның әлеге Нигезләмә таләпләренә туры килмәве;
- документларның тапшырылмавы (тулы булмаган комплектын тапшыру) һәм аларның әлеге Нигезләмә таләпләренә туры килмәве;
- тапшырылган мәгълүматның дөрес булмавы;
- заявкаларны һәм (яисә) документларны заявкаларны кабул итү срогы тәмамланганнан соң тапшыруы.

Грантка дәгъва кылучыга сайлап алу нигезендә катнашудан баш тарткан очракта, Вәкаләтле орган эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә, әлеге Нигезләмәнең 15 пунктының беренче абзацында күрсәтелгән срок узгач, грантка дәгъва кылучыга тиешле хәбәрнамә җибәрә.

17. Грантка дәгъва кылучыны сайлап алу үз эченә түбәндәгеләрне ала:

- портфолионы бәяләү;
- проектны бәяләү.
- Заявкаларны бәяләү балларда түбәндәге критерийлар буенча гамәлгә ашырыла:
- портфолионы бәяләү критерийлары (читтән торып үткәрелә торган этап):
- педагогик эшчәнлек эшен вазыйфаи бурычларны исәпкә алып оештыру (укытыла торган предметның үзенчәлеген исәпкә алып, укучыларны укыту

нәтиҗәләренең уңай динамикасы; бәхетсезлек очракларының булмавы; белем бирү процессын үткәрү шартларын яхшырту һәм савыктыру; семинарлар, «түгәрәк өстәлләр» аша квалификация күтәрү, һөнәри конкурсларда, күргәзмәләрдә, конференцияләрдә катнашу h. б.);

- аерым категориядәге балалар өчен эшчәнлек программаларын гамәлгә ашыруда катнашу;
- проектны бәяләү критерийлары (турыдан-туры катнашу этабы):
- эшчәнлекнең белем бирү оешмасына, муниципалитетка, регионга инновацион юнәлешле булуы, эшчәнлекнең аерым предметлары яисә профиле буенча белем бирү эшчәнлеген үстерү программаларын эшләү һәм гамәлгә ашыру;
- педагогик агартуга юнәлгәнлек (педагоглар үсешенең индивидуаль траекториясен төзүдә ярдәм итү, үзлегеннән белем алу дәрәҗәсен күтәрү);
- технологик юнәлеш (укучыларның белем алу таләпләрен мониторинглау, укучыларның нәтиҗәләрен диагностикалау).

18. Сайлап алу йомгаклары буенча җыелган баллар кими бару тәртибендә грантка дәгъва кылучылар исемлеге төзелә. Иң күп балл җыйган грантка дәгъва кылучы исемлектә иң югары позицияләрне били. Бер үк санда балл җыйган грантка дәгъва кылучы заявка бирү датасы буенча ранжлана.

Сайлап алу җиңүчеләре дип рейтингта иң югары позицияләрне алган грантка дәгъва кылучы таныла.

19. Грант Вәкаләтле орган грант бирү турында карар кабул иткән көннән алып 30 календарь көннән дә соңга калмыйча Башкарма комитет тарафыннан грант алучы белән төзелә торган килешүдә билгеләнгән тәртиптә бирелә (3 нче кушымта).

20. Килешүдә түбәндәгеләр карала:

- грант бирү максатлары;
- грант күләме;
- грант күчерү сроклары һәм тәртибе;
- проектны гамәлгә ашыру турында хисап бирү сроклары һәм тәртибе;
- грант алучының грант бирү шартларын, максатларын, тәртибен үтәвен тикшерүләрне Башкарма комитет һәм муниципаль финанс контроле органнары тарафыннан гамәлгә ашыруына ризалыгы;
- грантны кире кайтару очраклары һәм тәртибе;
- грантны мәҗбүри түләттерү буенча чаралар күрү сроклары;
- грант бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен бозган өчен җаваплылык.

21. Грант алучылар Вәкаләтле органга проектны гамәлгә ашыру турында килешүдә билгеләнгән форма һәм срокларда хисап бирәләр.

Проектны гамәлгә ашыру турында хисапта түбәндәгеләр күрсәтелә:

Грантны гамәлгә ашыру кысаларында иң яхшы педагогик тәҗрибәләрне таратуга юнәлдерелгән чаралар саны, проектны гамәлгә ашыру кысаларында уздырылган чараларның (алга таба – чаралар) әһәмияте (шул исәптән белем бирү оешмасы тарафыннан гамәлгә ашырыла торган белем бирү проектларын тәкъдир итү белән ачык чаралар саны – елына Зеленодольск муниципаль районы дәрәҗәсендә кимендә ике чара);

чарада катнашучылар саны.

22. Грант түләү ике яклы килешүдә билгеләнгән срокларда гамәлгә ашырыла: Грант алучы, Башкарма комитет.

23. Россия Федерациясенең бюджет законнары нигезендә Башкарма комитет һәм муниципаль финанс контроле органнары грант алучыларның грантлар бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвен тикшерәләр.

24. Башкарма комитет һәм муниципаль финанс контроле органнары үткәргән тикшерүләр йомгаклары буенча әлеге Нигезләмәдә төзелгән килешүдә билгеләнгән грант бирү шартларын һәм максатларын бозу факты ачыкланган очракта, Грант алучы алынган акчаларны Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының язма таләбен алган көннән алып 30 календарь көн эчендә ирекле тәртиптә Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджетына кире кайтара.

25. Грант алучы алган акчаларны Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджетына кире кайтарудан баш тарткан көннән алып календарь көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджеты керемнә акчаларны ирекле кире кайтарудан баш тарткан очракта  яисә Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджетына грант алучының алган акчаларын Башкарма комитетның язма таләбендә күрсәтелгән ирекле кире кайтару срогы узгач, алар Россия Федерациясе законнары нигезендә Башкарма комитет тарафыннан суд тәртибендә түләтелергә тиеш.

26. Гранттан нәтиҗәле файдалануны, аны бирү шартларының һәм тәртибенең үтәлешен тикшереп тору Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы
Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2024 елның 17 декабрендәге
4728 номерлы карарына
2 нче кушымта

«ЯШЬ БЕЛГЕЧ»
грантын алу өчен конкурс комиссиясе составы

**Комиссия рәисе**

| | |
|---|---|
| Афанасьева Рәисә Вәли кызы | Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары-Мәгариф идарәсе башлыгы |

**Комиссия рәисе урынбасарлары**

| | |
|---|---|
| Шатская Мария Николаевна | Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты Мәгариф идарәсенең мәгълүмат-методика бүлеге башлыгы |

**Комиссия әгъзалары:**

| | |
|---|---|
| Фесенко Ирина Владимировна | Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Зеленодольск шәһәре Советы депутаты |
| Гайсина Ольга Борисовна | Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты Мәгариф идарәсенең мәгълүмат-методика бүлеге өлкән методисты |
| Бобкова Татьяна Николаевна | Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты Мәгариф идарәсенең мәгълүмат-методика бүлеге методисты |
| Сәләхова Роза Әбрар кызы | Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты Мәгариф идарәсенең мәгълүмат-методика бүлеге методисты |
| Суховая Елена Владимировна | Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты Мәгариф идарәсенең мәгълүмат-методика бүлеге методисты |

Татарстан Республикасы
Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2024 елның 17 декабрендәге
4728 номерлы карарына
3 нче кушымта

«Яшь белгеч» грантын алу өчен конкурс нигезендә сайлап алу критерийлары

1. Грантка дәгъва кылучының белем бирү эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыру ысулларын һәм технологияләрен куллану буенча индивидуаль проектны бәяләү критерийлары

Һәр күрсәткеч балларда бәяләнә (10нан артык балл җыярга кирәк). Белем бирү эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру ысулларын һәм технологияләрен куллану буенча индивидуаль проектны бәяләү буенча максималь баллар саны 24 балл тәшкил итә.

| Дәрәҗә, баллар диапазоны | Бәяләүнең якынча эчтәлеге |
|---|---|
| 1. Тәкъдим ителә торган теманың актуальлеге | |
| Югары, 8 балл | Тәкъдим ителә торган теманың актуальлеге ышандырырлык дәлилләнгән. |
| Уртача, 6 балл | Тәкъдим ителә торган теманың актуальлеге тулаем дәлилләнгән, әмма экспертның бик әһәмиятле булмаган күрсәтмәләре бар(техник хаталар) . |
| Уртачадан түбән, 4 балл | Проектка концептуаль характердагы күрсәтмәләр бар: тәкъдим ителгән аргументлар теманың эчтәлегенә каршы килә; тәкъдим ителгән аргументларда практик (статистик) мәгълүматлар юк, бары тик теоретик яки тасвирлау характерындагы аргументлар гына файдаланылган. |
| Түбән, 0 балл | Тәкъдим ителә торган теманың актуальлеге, актуальлекне нигезли торган аргументлар булмау сәбәпле, дәлилләнмәгән |
| 2. Оригинальлек/кыйммәтлеге, практик әһәмияте | |
| Югары, 8 балл | Оригинальлек/кыйммәтлеге, практик әһәмияте, ышандырырлык итеп дәлилләнгән. |
| Уртача, 6 балл | Практик әһәмияте бар, әмма оригинальлек / кыйммәтлеге юк. |
| Уртачадан түбән, 4 балл | Оригинальлек/кыйммәтлеге бар, әмма практик әһәмияте юк. |
| Түбән, 0 балл | Оригинальлек/кыйммәтлеге, практик әһәмияте дәлилләнмәгән |
| 3. Зеленодольск муниципаль районына тәҗрибә тарату мөмкинлеге | |
| Югары, 8 балл | Тарату мөмкин һәм тәкъдим ителгән. |
| Уртача, 4 балл | Тарату мөмкин, әмма экспертның бик әһәмиятле булмаган күрсәтмәләре бар. Эшләп бетергәннән соң тарату мөмкин. |
| Түбән, 0 балл | Тарату мөмкин түгел/тәкъдим ителмәгән. |

Татарстан Республикасы
Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2024 елның 17 декабрендәге
4728 номерлы карарына
4 нче кушымта

«Яшь белгеч» грантын алу өчен конкурс нигезендә сайлап алу сроклары һәм тәртибе

| «Яшь белгеч» грантын алу өчен конкурс нигезендә сайлап алу этаплары | Оптималь сроклар | Этапны уздыру даталары |
|---|---|---|
| Конкурс нигезендә сайлап алу, грантка дәгъва кылучыга карата таләпләр, электрон әйләнеш документлары чаралары буенча конкурс нигезендә сайлап алу сроклары турында мәгълүмат бирү. | Сайлап алу башланганчы 7 календарь көн | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән раслана |
| Грантка дәгъва кылучыны конкурс нигезендә сайлап алуда катнашу турында заявкалар кабул итү һәм теркәү | 3 календарь көн | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән раслана |
| Конкурс комиссиясе тарафыннан заявкаларны карап чыгу һәм грант турындагы карар белән расланган Грант турындагы нигезләмәнең таләпләренә туры килүенә грантка дәгъва кылучының тапшырылган документларына һәм материалларына экспертиза ясау | 10 эш көне | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән раслана |
| Грант турында нигезләмәдә расланган заявканың таләпләргә туры килмәве сәбәпле, грант алу өчен катнашучыга конкурс нигезендә сайлап алуда катнашудан баш тарту турында хәбәрнамәләр җибәрү | Заявкалар каралганнан соң 5 эш көне | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән раслана |
| Йомгаклау. Җиңүчеләрне билгеләү ( грантка дәгъва кылучының баллар саны бертигез булган очракта, тавыш бирүне исәпкә алып) | 2 эш көне | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән раслана |
| Грант алучыларның исемлеген Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты боерыгы белән раслау. Электрон әйләнеш документының чаралары буенча сайлап алу йомгаклары турында мәгълүмат урнаштыру | Җиңүчеләрне билгеләгәннән соң 7 календарь көн | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән раслана |
| Грант бирү турында килешүләр төзү | 30 календарь көн | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән раслана |

Татарстан Республикасы
Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2024 елның 17 декабрендәге
4728 номерлы карары белән
расланган Нигезләмәгә
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе ведомствосындагы
муниципаль белем бирү оешмалары һәм балаларга өстәмә белем бирү
оешмаларының педагог хезмәткәрләре арасыннан грантка дәгъва кылучының
заявка формасы

Теркәлү номеры:
Заявканы теркәү датасы:
(документлар һәм материаллар кабул итү операторы тарафыннан тутырыла)

Раслыйм

Педагог хезмәткәрләре арасыннан грантка дәгъва кылучыны тәкъдим итүче Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе ведомствосындагы муниципаль белем бирү оешмалары һәм балаларга өстәмә белем бирү оешмалары җитәкчесе_______________________________
_________________________________________
________________________________________
(муниципаль берәмлек исеме)

____________________/_____________
(имза/имзаның аңлатмасы)
"____" _______________20___ел

М.У.

«Яшь белгеч» грантын дәгъва кылу өчен заявка

Мин, ________________________________________________________________,
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы - булган очракта, туган елы)
______________________________________________________________________
(югары уку йортының, факультетның исеме, тәмамлану елы)
чыгарылыш сыйныф укучысы
____________________________________________________________________________(
(диплом буенча белгечлек исеме)
____________________________________________________________________________
_______________________________________________________ белгечлек буенча

______________________________________________________________________
(гомуми белем бирү оешмасының тулы исеме)
____________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________
Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы территориясендә урнашкан Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе ведомствосындагы муниципаль белем бирү оешмасына яисә балаларга өстәмә белем бирү оешмасына эшкә урнаштырылган

_______________________________________________________________________

(укыту предметының исеме)

__________________________________________________Укытучы/тәрбияче

«Яшь белгеч» грантына дәгъва кылу өчен минем кандидатурамны каравыгызны сорыйм һәм түбәндәге мәгълүматны бирәм

1. Укыту предметын һәм йөкләнеш күләмен күрсәтеп, грант алу өчен сайлап алуда катнашуның уку елына педагогик йөкләнеш турында мәгълүматлар: _______________________________________________________

_____________________________________________________________________________

Педагогик эшнең гомуми стажы

____________________________________________________

Белгечлек буенча эш стажы

_________________________________________________________

2.Теркәү буенча яшәү урыны адресы (почта индексын күрсәтеп): _____________________________________________________

_________________________________________________________________________

Яшәү урынының факттагы адресы (почта индексын күрсәтеп):

_____________________________________________________________________________

_____________________________________________________________________________

_____________________________________________________________________________

Контакт телефоны (яшәү урынының кодын күрсәтеп): _________________________

Кәрәзле телефон номеры

____________________________________________________________

Электрон почта адресы:

_____________________________________________________________

3. Сез Татарстан Республикасы бюджеты яки муниципаль берәмлек бюджеты акчалары исәбеннән кайчан да булса берәр грант алдыгызмы? ___________________________________

(әйе, юк)

Әгәр әйе икән, грант алу елын, проектның исемен һәм грант күләмен күрсәтегез:

_____________________________________________________________________________

_____________________________________________________________________________

_____________________________________________________________________________

_____________________________________________________________________________

4. Сайлап алуга тәкъдим ителгән дәрес һәм дәрестән тыш эшчәнлек нәтиҗәлелеген арттыру ысулларын һәм технологияләрен куллану буенча индивидуаль проект исеме (алга таба - проект)__________________________________________________

_____________________________________________________________________________

_____________________________________________________________________________

_____________________________________________________________________________

_____________________________________________________________________________

Әлеге заявка белән грантка дәгъва кылучы «Яшь белгеч» грантын гамәлгә ашыру шартлары белән танышуын раслый, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә грантка дәгъва кылучы турында, грантка дәгъва

кылучы тапшырган заявка турында, грантка дәгъва кылучы турында тиешле сайлап алуга бәйле башка мәгълүматны бастырып чыгаруга (урнаштыруга) ризалык бирә.

_______________________________________________________________/___________

__________________________________________________________________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда)

(имза)

«_____»____________, 20___ ел

Татарстан Республикасы
Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2024 елның 17 декабрендәге
4728 номерлы карары белән
расланган Нигезләмәгә
2 нче кушымта

Форма

«Яшь белгеч» грантына дәгъва кылучының персональ мәгълүматларын эшкәртүгә ризалыгы

Татарстан Республикасы
Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитеты
ИНН: 1648017863, ОГРН: 1061673000993
Адресы: 422540, Зеленодольск ш., Ленин ур., 41 нче А йорты
Татарстан Республикасы
Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитеты Мәгариф идарәсе
Адресы: 422540, Зеленодольс ш., Ленин ур., 38 нче йорт

_________________________________________
________________________________________
(персональ мәгълүматлар субъектының фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы - булган очракта)
телефон номеры, электрон почта адресы яисә почта адресы:
_________________________________________
________________________________________

Персональ мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык

Мин, ______________________________________________________________,
(персональ мәгълүматлар субъектының фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы - булган очракта)

_______________________________________________________________
(персональ мәгълүматлар субъектының шәхесен таныклаучы документ)
_______________________________________________________________
_______________________________________________________________

2006 елның 27 июлендәге«Персональ мәгълүматлар турында» 152-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясы, Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең 2021 елның 24 февралендәге «Тарату өчен персональ мәгълүматлар субъекты тарафыннан рөхсәт ителгән персональ мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык эчтәлегенә таләпләрне раслау турында» 18 номерлы боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына

(алга таба – ТР ЗМР БК) һәм Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе (алга таба-Мәгариф идарәсе )вәкиленә, ведомство буйсынуындагы оешмага шул исәптән https://mon.tatarstan.ru, https://doc.tatar.ru мәгълүмати ресурсларыннан файдаланып, «Яшь белгеч» грантына дәгъва кылу өчен конкурс нигезендә сайлап алуда катнашу кысаларында һәм конкурста җиңгән очракта - «Яшь белгеч» грантын бирү турындагы килешүнең гамәлдә булу чорына үземнең персональ мәгълүматларымны эшкәртүгә (тапшыруга, бирүгә, таратуга) ризалыгымны бирәм.

Эшкәртелә торган персональ мәгълүматлар исемлеге:

1) персональ мәгълүматлар: фамилия, исем, атасы исеме (соңгысы - булган очракта), елы, ае, туу датасы, яшәү урыны һәм теркәлү адресы, гаилә хәле, белеме;

2) персональ мәгълүматларның махсус категорияләре: хезмәт стажы (хезмәт кенәгәсе күчермәсе) турында белешмәләр; паспорт мәгълүматлары; ИНН күрсәткечләре; иминият пенсия таныклыгы номеры.

2006 елның 27 июлендәге«Персональ мәгълүматлар турында» 152-ФЗ номерлы Федераль закон һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары нигезендә персональ белешмәләрне җыю, системалаштыру, туплау, саклау, төгәлләштерү (яңарту, үзгәртү), куллану (шул исәптән тапшыру), зарарсызлау, блоклау, юкка чыгару кебек персональ мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык бирелә торган персональ мәгълүматлар белән гамәлләр исемлеге.

Оператор персональ мәгълүматларны персональ мәгълүматлар субъектының персональ мәгълүматларын эшкәртүнең автоматлаштырылган чараларын кулланып та, автоматлаштыру чараларын кулланмыйча да эшкәртә.

Персональ мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык биргән срок: әлеге ризалык аңа кул куйган көннән алып персональ мәгълүматларны язма рәвештә кире алган көнгә кадәр гамәлдә була.

Персональ мәгълүматлар субъекты эшкәртү өчен шартлар һәм тыюлар билгели торган персональ мәгълүматлар белешмәләр категорияләре һәм исемлеге, шулай ук билгеләнә торган шартлар һәм тыюлар исемлеге (персональ мәгълүматлар субъекты теләге буенча тутырыла):_______________________________________________________

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

Алынган персональ мәгълүматлар персональ мәгълүматларны эшкәртүне гамәлгә ашыручы оператор тарафыннан аның мәгълүматка бары тик катгый билгеләнгән хезмәткәрләр өчен генә керүне тәэмин итә торган эчке челтәре аша гына йә мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән файдаланып, йә алынган персональ мәгълүматларны тапшырмыйча гына тапшырыла торган шартлар (персональ мәгълүматлар субъекты теләге буенча тутырыла)

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

__________________________________________________________________

| ______________________________________ | ____________ | ____________ |
|---|---|---|
| (персональ мәгълүматлар субъекты Ф. И. Ат.и. (соңгысы – булган очракта), ) | (имза) | (дата) |

Татарстан Республикасы
Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2024 елның 17 декабрендәге
4728 номерлы карары белән расланган
Нигезләмәгә
3 нче кушымта

Форма

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты һәм Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы территориясендә урнашкан, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе ведомствосындагы муниципаль белем бирү оешмасы һәм балаларга өстәмә белем бирү оешмасының педагог хезмәткәре арасында «Яшь белгеч» грантын бирү турында конкурс нигезендә сайлап алу нәтиҗәләре буенча бер мәртәбә бирелә торган түләү бирү турында
КИЛЕШҮ

__________________ «___»_________ 20__ ел

Гамәлдәге Устав нигезендә, бер яктан, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе
_______________________________________________________________ йөзендә
(Башкарма комитет җитәкчесенең Ф.И.Ат.и.)
һәм Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы территориясендә урнашкан, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты Белем бирү идарәсе ведомствосындагы муниципаль белем бирү оешмасы һәм балаларга өстәмә белем бирү оешмасының педагогик хезмәткәре (алга таба- грант алучы) буйсынган (алга таба - грант алучысы)
_______________________________________________________________ икенче яктан,
(грант алучының Ф. И. Ат.и)
бергә Яклар дип аталучылар түбәндәгеләр турында әлеге Килешүне төзеделәр:

## 1. КИЛЕШҮ ПРЕДМЕТЫ

1.1. Әлеге Килешүнең предметы булып Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы территориясендә урнашкан, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты Мәгариф идарәсе ведомствосындагы муниципаль белем бирү оешмалары һәм балаларга өстәмә белем бирү оешмаларының педагогик хезмәткәрләренә бер мәртәбә бирелә торган түләү турында «Яшь белгеч» гранты турындагы нигезләмә кысаларында барлыкка килгән һәм гамәлгә ашырыла торган Якларның үзара мөнәсәбәтләре тора.

1.2. Әлеге Килешү нигезендә Грант алучы уку процессы нәтиҗәлелеген арттыруның инновацион алымнары һәм технологияләре проектын гамәлгә кертүне йөкләмә итеп ала_________________________________________
(проектның исеме)
_______________________________________________________________
(белем бирү оешмасының исеме)
________________эш бирүчедә (алга таба - проект) гамәлгә ашырыла торган шулай ук күрсәтелгән проект буенча Татарстан Республикасы Зеленодольск

муниципаль районы Башкарма комитеты Мәгариф идарәсенә (алга таба - Мәгариф идарәсе) хисап тапшырырга, Башкарма комитет Грант алучыга Башкарма комитетның__________ №_____ күрсәтмәсе нигезендә (Нигезләмә) бер тапкыр бирелә торган түләү бирергә йөкләмә ала.

## 2. Якларның бурычлары һәм хокуклары

2.1. Башкарма комитет түбәндәге хокукка ия:

2.1.1. Грант алучыдан әлеге Килешүнең барлык шартларын үтәүне таләп итәргә.

2.1.2. Уку планы һәм белем бирү оешмасының уставында һәм эчке тәртип кагыйдәләрендә каралган бурычларны үтәү нигезендә проектны гамәлгә кертү нәтиҗәләре турында Грант алучыдан мәгълүмат соратып алырга.

2.1.3. Әлеге Килешүнең 2.4.9 пунктында күрсәтелгән мәгълүматны Грант алучыдан таләп итәргә.

2.1.5. Грант алучы әлеге Килешүдә , шулай ук Нигезләмәдә каралган шартларны үтәмәгән очракларда түләү бирү турындагы карарны гамәлдән чыгарырга.

2.1.6. Грант алучы шушы Килешүнең 2.4.2, 2.4.7 пунктларында каралган , шулай ук 5.1.2, 5.1.3,5.1.4,5.1.5 пунктлары нигезендә йөкләмәләрне үтәмәгән очракта, Грант алучыдан грант түләүгә тотылган акчаларны Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджеты кеременә кайтаруны таләп итәргә.

2.2. Башкарма комитет түбәндәгеләргә бурычлы:

2.2.1 ел саен __________20_______ елга кадәр Грант алучының уку елы өчен башкарылган эше турында хисапларны, шулай ук хисап чорында Грант алучының бәяләмәсен (объектив характеристикасын) карарга.

2.2.2 Грант алучы гаебе белән Килешүне нигезсез сәбәпләр аркасында өзү турында карар кабул итәргә.

2.2.4 Грант алучы тарафыннан Киилешү шартларын бозган очракта, әлеге Килешүне берьяклы тәртиптә өзәргә.

2.3 Грант алучы түбәндәгеләргә хокуклы:

2.3.1 Башкарма комитеттан әлеге Килешүнең барлык шартларын үтәүне таләп итәргә.

2.3.2 Килешүнең 5.3 пункты нигезендә әлеге Килешүнең гамәлдә булуын берьяклы тәртиптә өзәргә.

2.4 Грант алучы түбәндәгеләргә бурычлы:

2.4.1 Әлеге Килешүнең һәм Кагыйдәләрнең шартларын үтәргә.

2.4.2 Әлеге Килешү буенча йөкләмәләрне үтәүне кыенлаштыра торган форс-мажор хәлләр башланганнан соң эш көннәре исәбеннән 20 көн эчендә, шушы Килешүнең шартларын үтәү мөмкинлеге булмау турында, сәбәпләрен дәлилләп күрсәтеп, Башкарма комитетка вакытында хәбәр итәргә.

2.4.3 әлеге Килешү 5.1.3, 5.1.4,5.1.5 пунктларында күрсәтелгән сәбәпләр аркасында, шулай ук 2.4.2, 2.4.7 пунктларында күрсәтелгән йөкләмәләрне үтәмәү сәбәпле вакытыннан алда өзелгән очракта, Грант түләүгә тотылган акчаларны кире кайтарырга.

2.4.4 үзенең контакт мәгълүматы (фамилиясе, яшәү адресы, телефон номеры һ.б.) үзгәргән очракта, эш көннәре исәбенннән 10 көн эчендә бу хакта Башкарма комитетка язмача хәбәр итәргә.

2.4.5 Грант алганнан соң Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы территориясендә муниципаль белем бирү оешмасында әзерлек юнәлеше

(профиле) буенча кимендә биш ел эшләргә.

2.4.6 әлеге Килешүнең 9 пунктында билгеләнгән, әлеге Килешүнең гамәлдә булу срогы тәмамланганчыга кадәр эш бирүче белән төзелгән хезмәт шартнамәсен өзүгә алып бара торган нинди дә булса гамәлләр кылырга яисә кылмаска.

2.4.7 хезмәт килешүен өзү турында Башкарма комитетка эштән китү көне алдыннан 1 эш көне эчендә хәбәр итәргә.

2.4.8 Грант алучыга түбәндәге очраклар килеп чыккан көннән алып ике ай эчендә түләнгән акчаларны кире кайтаруны гамәлгә ашырырга:

Грант алучының хезмәт шартнамәсен Кагыйдәләрнең 3 пункты өченче абзацында күрсәтелгән вакыттан алданрак өзүе.

3. Финанслау тәртибе

Әлеге Килешүне финанслауга бәйле чыгымнар ______________________________

(нигезләү документлары)

______________________________ нигәзендә гамәлгә ашырыла.

4. Якларның җаваплылыгы

5.

4.1 Яклар әлеге Килешү буенча йөкләмәләрне үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән очракта, алар Россия Федерациясе законнары, әлеге Килешү һәм Кагыйдәләр нигезендә җавап тоталар.

4.2 2.4.2, 2.4.7 пунктларында каралган үз йөкләмәләрен үтәмәгән очракта, шулай ук шушы Килешүнең 5.1.2, 5.1.3, 5.1.4, 5.1.5 пунктлары нигезендә Грант алучы законнарда билгеләнгән тәртиптә инфляция чыгымнарын исәпкә алып түләнгән чыгымнарны тулы күләмдә капларга, шулай ук вакыты чыккан очракта неустойка түләргә тиеш.

Әлеге Килешүдә каралган йөкләмәләрне үтәү вакыты чыккан һәр көн өчен неустойка исәпләнә. Мондый неустойканың күләме Грант алучыга әлеге Килешүдә каралган бурычларны үтәү вакытын кичектергән һәр көн өчен түләнгән акчаларның 0,01 процентын тәшкил итә.

4.3 Җиңеп булмаслык көч шартлары нәтиҗәсендә барлыкка килгән үз йөкләмәләрен тулысынча яисә өлешчә үтәмәгән очракта Яклар җавап тотмый.

6. Килешүне вакытыннан алда өзү (гамәлне туктатып тору) өчен нигезләр

5.1 Яклар тарафыннан әлеге Килешүне вакытыннан алда өзү өчен нигез булып түбәндәгеләр тора:

5.1.1 Яклар тарафыннан әлеге Килешүнең шартларын үтәмәве.

5.1.2 Яклар тарафыннан алдан ук дөрес булмаган белешмәләр бирүе.

5.1.3 уку елы өчен белем бирү оешмасы бәяләмәсе нигезендә Грант алучы тарафыннан педагогик эшчәнлегенең нәтиҗәсезлеге.

5.1.4 белем бирү оешмасы тарафыннан Грант алучының педагогик эшчәнлегенә канәгатьсезлек белдерелгән бәяләмә бирүе.

5.1.5 Үз теләге белән Грант алучының хезмәт шартнамәсен өзүе.

5.2 Әлеге Килешүне нигезле сәбәпләр аркасында Башкарма комитет инициативасы белән вакытыннан алда өзү өчен нигез булып түбәндәгеләр тора:

5.2.1 Башкарма комитетның бетерелүе.

5.3

Әлеге Килешүне нигезле сәбәпләр аркасында Грант алучы инициативасы белән вакытыннан алда өзү өчен нигез булып түбәндәгеләр тора:

5.3.1 Грант алучының педагогик хезмәт эшчәнлеген алып баруга комачаулый торган, тиешле документлар белән расланган авыруы.

5.3.2 Белем бирү оешмасында педагогик хезмәт эшчәнлеген алып баруга комачаулый торган, тиешле документлар белән расланган авыруы.

## 6.Килешүне үзгәртү һәм өзү тәртибе

6.1 Элеге Килешү шартлары Яклар ризалыгы белән үзгәртелергә мөмкин.

6.2 Әлеге Килешүне гамәлдән чыгару яки туктатып тору өчен, моны теләгән Як икенче Якка, Килешүне өзү яки туктатып тору өчен нигезләрне раслый торган документларны беркетеп, язмача хәбәрнамә җибәрә. Язма хәбәрнамәгә җавап, хәбәрнамә алынган көннән алып, 15 (унбиш) календарь көн эчендә бирелергә тиеш.

6.3 Әлеге Килешүнең 5.2,5.3 пунктлары нигезендә җитди сәбәпләр аркасында әлеге Килешү өзелгән очракта, Грант алучыга түләнгән акчалар кире кайтарылмый.

## 7. Форс-мажор

7.1 Әгәр бурычларны үтәмәү, әлеге Килешүне төзегәннән соң, Яклар алдан күрә яки булдырмый кала алмаган гадәттән тыш характердагы хәлләр нәтиҗәсендә килеп чыккан, җиңеп булмаслык көч шартлары нәтиҗәсе булган очракта, Яклар әлеге Килешү буенча бурычларны өлешчә яки тулысынча үтәүдән азат ителәләр

Җиңеп булмаслык көчләр шартларына Яклар йогынты ясый алмаган һәм аларның килеп чыгышына җаваплылык тотмый торган вакыйгалар керә (җир тетрәү, янгын, инвалидлык алу, психик авыру, забастовкалар, дәүләт хакимияте органнары карары яки боерыгы һ.б.).

7.2 Җиңеп булмаслык көчләр шартларына сылтаучы Як түбәндәгеләргә бурычлы:

7.2.1 Җиңеп булмаслык көчләр шартлары туган көннән алып, эш көннәре исәбеннән 20 көнлек срокта Якларга мондый хәлләр килеп чыгуы турында язмача формада хәбәр итәргә, өстәвенә, икенче Як таләбе буенча, дәүләт оешмасыннан алынган раслаучы документ бирелергә тиеш. Мәгълүматта шартларның характеры, шулай ук Якларның әлеге Килешү буенча бурычларны үтәвенә һәм бурычларны үтәү срогына аларның йогынтысын (мөмкин булганча) бәяләү турында белешмә булырга тиеш.

7.2.2 Күрсәтелгән хәлләр тәмамланганнан соң, тиз арада бу хакта икенче Якка язмача хәбәр итәргә. Шул ук вакытта әлеге Килешү буенча йөкләмәләрне үтәүнең фаразланган вакыты күрсәтелергә тиеш. Әгәр хәбәр итү кәгазе җибәрелмәгән яки вакытында җибәрелмәгән булса, чыгымнар әлеге шартларда калган Як тарафыннан кайтарыла.

## 8. Каршылыкларны карау тәртибе

8.1 Әлеге Килешүдәге яки аңа бәйле рәвештә уртак фикергә килүче Яклар арасында туарга мөмкин барлык бәхәсләр һәм фикер каршылыклары сөйләшүләр юлы белән хәл ителергә тиеш.

8.2 Сөйләшүләр юлы белән килешүгә ирешү мөмкин булмаган очракта бәхәсләр суд тәртибендә карала.

8.3 Әлеге Килешү белән җайга салынмаган барлык мәсьәләләр буенча Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нормалары кулланыла.

## 9. Килешүнең гамәлдә булу вакыты

Әлеге Килешү Яклар тарафыннан имзаланган көннән үз көченә керә һәм Якларның аның буенча барлык йөкләмәләрен тулысынча үтәгәнче гамәлдә була.

10. Башка шартлар

10.1 Әлеге Килешүгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр Яклар тарафыннан бары тик үзара ризалык нигезендә, әлеге Килешүдә һәм законнарда билгеләнгән шартларны үтәп, әлеге Килешүнең аерылгысыз өлеше булып торачак өстәмә килешү төзү юлы белән генә кертелергә мөмкин.

10.2 Әлеге Килешү рус телендә һәр Як өчен берәр данә бертигез юридик көчкә ия булган ике нөсхәдә төзелде.

10.3 Яклар әлеге Килешүнең һәр пунктын игътибар белән өйрәнделәр, аңладылар һәм килештерделәр, соңыннан мәҗбүр ителмичә, үз теләкләре белән аңа имза куйдылар.

11. Якларның адреслары, реквизитлары һәм имзалары

**Башкарма комитет**

Татарстан Республикасы
Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитеты

____________________/_________________
(Имза)

«______» _________ 20___________ел.

**Граждан**

Фамилиясе, исеме, атасының исеме:_________________
.
Туу датасы: ________________
Туган урыны:__________________________
Адресы: _________________________
.
Паспорты:
________________________________
.
.

____________________/_________________
(Имза)

«______» _________ 20________ ел

Расланган
Татарстан Республикасы
Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2024 елның 17 декабрендәге
4728 номерлы карары белән

Грантка дәгъва кылучының документларын һәм материалларын рәсмиләштерүгә таләпләр

Грантка дәгъва кылучының һәрберсенә документлар һәм материаллар белән аерым папка формалаша. Грантка дәгъва кылучының барлык материаллары бер папкага (файлларны беркетеп куя торган йомшак папкага) төркемләнә, ул 3 файлдан тора.

Беренче файлга папканың Титул бите һәм битләрен күрсәтеп кушып бирелгән документлар исемлеге кертелә.

Исемлек:

«Яшь белгеч» грантына дәгъва кылу өчен заявка ___б., 1 нөсх. ;

Грантка дәгъва кылучының персональ мәгълүматларны эшкәртүгә ризалыгы ___б., 1 нөсх. ;

Грантка дәгъва кылучының паспорт 1 күчермәсе___б., 1 нөсх. ;

эш бирүче яисә эш бирүченең башка вәкаләтле заты тарафыннан таныкланган белеме һәм (яисә) квалификациясе турында диплом күчермәсе___б., 1 нөсх. ;

аспирантура һәм фәннәр кандидаты дипломының күчермәсе(булган очракта)___б., 1 нөсх.;

грантка дәгъва кылучының эш урыны буенча таныкланган хезмәт кенәгәсенең яисә тиешенчә таныкланган электрон хезмәт кенәгәсенең күчермәсе___б., 1 нөсх. ;

грантка дәгъва кылучының кәгазьдә һәм (яисә) электрон саклагычта (раслаучы документлар кушымтасы белән) һөнәри казанышлары турында мәгълүматны үз эченә алган җитәкчесе яисә эш бирүченең башка вәкаләтле заты тарафыннан таныкланган белешмә__б., 1 нөсх. ;

салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият җыемнары, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурычның булмавы турында белешмә__б., 1 нөсх.;

эш урыны буенча таныкланган грамоталарның, сертификатларның, дипломнарның һәм башка документларның (алар булганда) күчермәләрен үз эченә алган портфолио __б., 1 нөсх. ;

дәрес һәм дәрестән тыш эшчәнлекнең нәтиҗәлелеген арттыру алымнарын һәм технологияләрен куллану буенча индивидуаль проект__б., 1 нөсх. ;

Титул битендә грантка дәгъва кылучының ФИАт. и., вазыйфасы (грантка дәгъва кылучының белгечлеге) һәм эш урыны (гомуми белем бирү оешмасы исеме) булырга тиеш;. Конкурс документларын тутырганда сайлап алуда катнашучының фамилиясе, исеме, атасының исеме паспортта язылганга туры китереп тутырыла;.

Икенче файлга грантка дәгъва кылучының документлар пакеты кертелә;. Әлеге документлар пакеты тегелгән (брошюратор, җеп, каты тышлык һ.б.), Битләр беренче биттән башлап номерланган булырга тиеш.;. Номерланган һәм брошюраланган документларның бөтен пакетын грантка дәгъва кылучы эшли торган белем бирү оешмасы җитәкчесе вәкиле раслый;..

Документлар түбәндәге тәртиптә урнаштырылырга тиеш:.

«Яшь белгеч» грантына дәгъва кылучының заявкасы;.

грантка дәгъва кылучының персональ мәгълүматларны эшкәртүгә ризалыгы;.

грантка дәгъва кылучының паспорт күчермәсе;

эш бирүче җитәкчесе яисә эш бирүченең башка вәкаләтле заты тарафыннан таныкланган белеме һәм (яисә) квалификациясе турында диплом күчермәсе;

грантка дәгъва кылучының эш урыны буенча таныкланган хезмәт кенәгәсенең яисә тиешенчә таныкланган электрон хезмәт кенәгәсенең күчермәсе;

грантка дәгъва кылучының кәгазьдә һәм (яисә) электрон саклагычта (раслаучы документлар кушымтасы белән)һөнәри казанышлары турында мәгълүматны үз эченә алган  җитәкче яисә эш бирүченең башка вәкаләтле заты тарафыннан таныкланган белешмә;

салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият җыемнары, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурычның булмавы турында белешмәләр;.

Әлеге документлар пакеты тегелгән һәм белем бирү оешмасы җитәкчесе мөһере белән беркетелгән булырга тиеш.

Өченче файлда  проект урнаштырылырга тиеш(номерланган битле, тегелгән). белешмәләр; Проектның титул битендә проектның исеме, грантка дәгъва кылучының ФИАт.и., вазыйфасы (грантка дәгъва кылучының белгечлеге) һәм эш урыны (гомуми белем бирү оешмасы исеме) булырга тиеш.

Документларны заявкалар кабул итүнең билгеләнгән срокларында тапшырырга кирәк.;.  Документлар Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсенә түбәндәге адрес буенча кабул ителә: Зеленодольск шәһәре, Ленин урамы, 38 йорт., 1 кат..; Эш графигы: 08.00 - 16.00 сәгатьләрдә.;. Контакт телефоны +7 919 642-16-15

Тапшыруга тәкъдим ителгән заявка кабул итү һәм теркәүнең соңгы көнендә 16:00 сәгатьтән соң кабул ителми.